ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.12.2024**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 5484**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 11 маендагы 1389 номерлы карары белән расланган, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда Зеленодольск муниципаль районында казначылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 24.4 бүлеге нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 11 маендагы 1389 номерлы карары белән расланган, Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очракларда Зеленодольск муниципаль районында казначылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 өлешнең 1 пунктында «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән билгеләнгән (алга таба тексты буенча - район) », сүзләреннән соң «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Кодексның 220.2 статьясы нигезендә, әлеге Тәртипнең беренче өлешенең 1 пункты нигезендә билгеләнгән акчаларны казначылык белән тәэмин итү (алга таба - максатчан акчалар) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 5 пункты нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 3 пункты нигезендә Федераль казначылык тарафыннан муниципаль берәмлекнең финанс органының аерым функцияләрен башкарганда (алга таба - финанс органы) гамәлгә ашырыла»;

1.3. 2 өлешнең 6 пунктының в) пунктчасында:

1.3.1. беренче абзацта «юридик затка» сүзләрен «казначылык белән тәэмин итүдә катнашучыга» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.2 икенче абзацта «юридик затның» сүзләрен «казначылык белән тәэмин итүдә катнашучының» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.3. өченче абзацта «юридик затның» сүзләрен «казначылык белән тәэмин итүдә катнашучының» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.4. дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

–« - товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү өчен казначылык белән тәэмин итүдә катнашучы товарлар, эшләр, хезмәтләр китерүче башка юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны җәлеп итмәгән очракта, шулай ук казначылык белән тәэмин итүдә катнашучының акчалата йөкләмәләре барлыкка килүен раслый торган Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.23 статьясындагы 4 пунктында каралган тиешле санкцияләү тәртибе белән билгеләнгән документларны һәм (яисә) муниципаль контрактларда, шартнамәләрдә (килешүләрдә), контрактларда (килешүләрдә) яки акча бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда (хокукый актларда) каралган башка документларны тапшыру шарты белән казначылык белән тәэмин итүдә катнашучы тарафыннан фактта китерелгән товарлар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр өчен финанс тәэмин итү чыганагы булып муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр), контрактлар (килешүләр) нигезендә бирелгән акчалардан торган түләүләр»;

1.3.5. бишенче абзацта «юридик зат белән» сүзләрен «казначылык белән тәэмин итүдә катнашучы белән» сүзләренә алмаштырырга;

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru/) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин